РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ
БУИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

---

РЕШЕНИЕ Буа шәһәре КАРАР

16 март 2026 ел № 2-8

Буа муниципаль районы Советының 2021 елның 22 ноябрендәге 2-21 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы муниципаль берәмлекләрендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советы карар кабул итте:

1. Буа муниципаль районы Советының 2021 елның 22 ноябрендәге 2-21 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы муниципаль берәмлекләрендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 29 статьяның 1 өлешендәге 5 пунктында «аларның вәкилләре,» сүзләреннән соң «үз-үзен җайга салучы оешма вәкилләре, әгәр контрольдә тотылучы зат өчен үз-үзен җайга салучы оешмада мәҗбүри әгъзалык каралган булса,» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны Буа муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга. http://pravo.tatarstan.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Буа муниципаль районы башлыгы,
Совет рәисе Р.Р. Камартдинов